**2024 елның беренче кварталында Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр белән эшләү турында мәгълүмат**

2024 елның беренче кварталында Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарында гражданнардан язмача кергән һәм шәхси кабул итүдә алынган **2049** мөрәҗәгать карап тикшерелде (2023 елда – 1976).

Мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан:

**1383** – язмача мөрәҗәгатьләр (2023 – 1143), шул исәптән электрон почта аша кергән мөрәҗәгатьләр – **899** (2023 – 775).

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе адресына 1220 гариза бирүчедән 45 коллектив мөрәҗәгать керде.

1383 мөрәҗәгатьнең 332 се уңай хәл ителде, бу гомуми санның 24,0 % ын тәшкил итә, 36 мөрәҗәгать ведомство буйсынуындагы оешмаларга адресланды, калганнары буенча аңлатмалар һәм рекомендацияләр бирелде.

Мөрәҗәгать итүчеләр арасында үз социаль хәлен күрсәткән гражданнар түбәндәге категорияләргә бүленә:

- эшләүчеләр: 106 (7,66 %);
- пенсионерлар: 94 (6,8 %);
- эшмәкәрләр: 17 (1,23 %);
- эшсезләр: 10 (0,72 %);
- хезмәткәрләр: 8 (0,58 %);
- хуҗабикәләр: 7 (0,51 %);
- интеллигенция: 3 (0,22 %);
- укучылар: 2 (0,15 %);
- социаль хәлен күрсәтмәүчеләр: 1136 (82,13 %).

Льготалы категориягә ия булуларын күрсәткән мөрәҗәгать итүчеләр арасында күпчелекне күп балалы гаиләләр – 37 (2,68 %), инвалидлар – 18 (1,3 %), хәрби хәрәкәт ветераннары – 6 (0,43 %) кешене тәшкил итте.

Гражданнардан кергән язмача мөрәҗәгатьләрне анализлаудан күренгәнчә, 2024 елның 1 кварталында шәһәрдәшләр өчен түбәндәге мәсьәләләр актуальрәк булып саналган:

- торак-коммуналь хуҗалыгы – 434 (2023 – 422);

- юл хуҗалыгы – 273 (2023 – 128);

- җирдән файдалану – 107 (2023 – 80);

- мәгариф һәм мәктәпкәчә тәрбия бирү – 75 (2023 – 65);

- торак өлкәсе – 72 (2023 – 64);

- төзелеш – 69 (2023 – 53);

- транспорт хезмәте күрсәтү – 58 (2023 – 54);

- сәүдә һәм кулланучылар хезмәте – 57 (2023 – 29);

- РФ Кораллы Көчләрендә хезмәт итү мәсьәләләре – 51 (2023 – 25);

- социаль тәэмин итү – 49 (2023 – 50);

- сәламәтлек саклау – 41 (2023 – 52);

- хезмәт һәм мәшгульлек – 20 (2023 – 14);

- финанс өлкәсе – 19 (2023 – 30);

- законлылык һәм хокук тәртибен тәэмин итү – 19 (2023– 30);

- элемтә мәсьәләләре – 7 (2023 – 13);

- башкалар – 32 (2023 – 34).

**666** чаллылы шәхси кабул итү вакытында кабул ителде (2023 – 833).

**250** мөрәҗәгать буенча кирәкле чаралар күрелде, мөрәҗәгать иткән **402** гражданга аңлатмалар бирелде, **14** мөрәҗәгать контрольдә тора.

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан турыдан-туры **36 чаллылы** кабул ителде.

Гражданнар һәр атнаның сишәмбе көннәрендә түбәндәгечә кабул ителә:

- шәһәр Хакиме, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан 16.00 дән 18.00 сәгатькә кадәр, Академик Рубаненко бульвары, 7 йорт адресы буенча урнашкан шәһәр Хакименең җәмәгатьчелекне кабул итү бинасында;

- шәһәр Хакиме ярдәмчесе (халык белән эшләү буенча) тарафыннан шимбә һәм якшәмбедән кала һәр көнне 08.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке ял вакыты – 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр, Академик Рубаненко бульвары, 7 йорт адресы буенча урнашкан шәһәр Хакименең җәмәгатьчелекне кабул итү бинасында.

- район хакимиятләре Башлыклары тарафыннан:

1. Автозавод районы – Шамил Усманов урамы, 112 (49/09) йорт, 2 этаж, 201 кабинет, 14.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;

2. Комсомол районы – Муса Җәлил проспекты, 56 йорт (ГЭС пос., 8/7а йорты), 2,5 этаж, 251 кабинет, 14.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;

3. Үзәк районы – Энтузиастлар бульвары, 11 (3/08) йорт, 3 этаж, 301 кабинет, 14.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;

- Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарлары, идарә башлыклары тарафыннан 14.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт адресы буенча урнашкан шәһәр хакимияте бинасында;

Җирле үзидарә органнарында гражданнарның бер генә мөрәҗәгате дә игътибарсыз калмый.

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең мониторингы көн саен үткәрелә, аларны үз вакытында карап тикшерү контрольдә тотыла, башкару дисциплинасына анализ ясала.

Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән мәсьәләләр компетенция кысаларында, оператив рәвештә хәл ителә.

Һәр мөрәҗәгать итүчегә гамәлдәге законнарга нигезләнгән язмача җаваплар һәм аңлатмалар бирелә.